СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

« 23 » июнь 2020 ел № 334

**Территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен башкару өлешендә территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлтелгән чаралар үткәрү өчен финанслау чыганагы Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар булган Арча муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 статьясы нигезендә Арча район Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен башкару өлешендә территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлтелгән чаралар үткәрү өчен финанслау чыганагы Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар булган Арча муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибен расларга.

2. Әлеге карар 2020 ел бюджетларыннан башлап (2021, 2022 еллар план чорына), Арча муниципаль районының берләштерелгән бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. 2020 елның 1 гыйнварыннан Арча район Советының «Арча муниципаль районында территориаль иҗтимагый үзидарәләргә ярдәм итү турында» 2014 елның 2 октябрендәге 291.1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk/tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.Г. Нуриев

Арча район Советының
23 июнь 2020ел, № 334
карары белән расланган

Территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен башкару өлешендә территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлтелгән чаралар үткәрү өчен финанслау чыганагы Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар булган Арча муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү
Тәртибе

1. Әлеге Тәртип территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен башкару өлешендә территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлтелгән чаралар үткәрү өчен финанслау чыганагы Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар булган Арча муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү механизмын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар тиешле җирлекләр территориясендә теркәлгән территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өчен шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар әлеге максатларга Арча муниципаль район Советының тиешле финанс елына һәм план чорына Арча муниципаль районы бюджеты турындагы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре күләме чикләрендә бирелә.

4. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен баш бүлүче булып Арча муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тора.

5. Җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертларны бүлү Арча муниципаль районы Башкарма комитетының норматив хокукый акты белән раслана.

6. Башка бюджетара трансфертлар бирү өчен Арча муниципаль районы җирлекләрен сайлап алу критерийлары:

җирлек территориясендә теркәлгән территориаль иҗтимагый үзидарәләр (алга таба – территориаль иҗтимагый үзидарәләр) булу;

ТИҮдә кеше саны шәһәр җирлеге өчен 80нән дә ким түгел, авыл җирлекләре өчен 2000 кешедән дә ким түгел.

7. Җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары:

а) җирлекләрнең Башкарма комитеты җитәкчеләренә компенсация түләнә торган территориаль иҗтимагый үзидарәләр исемлеген раслау турында боерыгы булу;

б) ТИҮ җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру буенча чыгым йөкләмәләрен билгеләүче җирлекнең билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән муниципаль хокукый акты булу.

8. Башка бюджетара трансфертларны куллануның нәтиҗәлелек күрсәткече булып ТИҮ җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыруга ярдәм иткән ТИҮләр саны тора.

9. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен җирлекләр Башкарма комитетка түбәндәгеләрне тапшыралар:

әлеге карар белән расланган форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирү өчен гариза;

ТИҮ оештыру документларының күчермәләре;

ТИҮ җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыруга финанс ихтыяҗын исәпләү һәм нигезләү.

Документлар җирлек тарафыннан язмача һәм электрон рәвештә тапшырыла.

10. Башка бюджетара трансфертлар Башкарма комитет һәм җирлекләр арасында әлеге карар белән расланган форма нигезендә төзелә торган килешү (алга таба - Килешү) нигезендә бирелә.

11. Килешүдә карала:

башка бюджетара трансфертларның күләме, аларның максатчан билгеләнеше;

башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткече;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе;

башка бюджетара трансфертлардан файдалану һәм башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченә ирешү турында хисап бирү сроклары һәм формалары;

башка бюджетара трансфертларны алучының билгеләнгән башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелегенең билгеләнгән күрсәткеченә ирешмәү нәтиҗәләре;

Килешүдә каралган башка бюджетара трансфертларның җирлек тарафыннан үтәлүен тикшереп тору тәртибе;

Килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы.

12. I-җирлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Pi = (N1 \times R1) \times 15 + (N2 \times R2) \times 15,$$

биредә:

Pi – ТИҮ җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өчен i-җирлегенең финанс ихтыяҗы, сум;

N1 - юридик затлар булган ТИҮ саны, берәмлекләр;

N2 - юридик затлар булмаган ТИҮ саны, берәмлек;

R1-юридик зат булган территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчесенә шәһәр (авыл) җирлеге өчен 13 020,0 сум күләмендә компенсация түләү күләме;

R2-юридик зат булмаган ТИҮ җитәкчесенә шәһәр (авыл) җирлеге өчен 10 0000,0 сум күләмендә компенсация түләү күләме.

13. Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү Килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлардан файдалану

нәтиҗәлелеге күрсәткечен һәм план елы нәтиҗәләре буенча фактта ирешелгән башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечен чагыштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

14. Башкарма комитет тарафыннан җирлекләр бюджетларына Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең территориаль органнарының касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган счетларына килешүдә билгеләнгән срокларда күчерелә.

15. Җирлекләр Башкарма комитетка башка бюджетара трансфертлардан файдалану һәм башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченә ирешү турында Килешүдә каралган срокларда һәм формада хисап тапшыралар.

16. Әлеге Тәртип нигезендә алынган агымдагы финанс елының 1 гыйнварына кулланылмаган башка бюджетара трансфертлар Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә Арча муниципаль районы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

17. Җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлар закон нигезендә тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөреслеге һәм башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын үтәү өчен җаваплы.

18. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары бозылган очракта, әлеге акчалар Россия Федерациясе Бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә Арча муниципаль районы бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

19. Әлеге Тәртип нигезендә бирелгән башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын законнар нигезендә Башкарма комитет һәм «ТР Арча муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ контрольдә тота.

Кушымта
Форма

Арча район Советының
23 июнь 2020 ел, №334
карары белән расланган

**Территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен башкару өлешендә территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлтелгән чаралар үткәрү өчен финанслау чыганагы Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар булган Арча муниципаль районы бюджетыннан җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү турында**

Килешү

Арча шәһәре

“___” ________________20__ел №

Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе___________________ исеменнән Нигезләмә нигезендә эш итүче, Арча муниципаль районы бюджеты акчаларын алучы буларак җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансферт бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары җиткерелгән Арча муниципаль районы башкарма комитеты, алга таба «Башкарма комитет» дип аталучы, бер яктан, __________________исеменнән Устав нигезендә эш итүче алга таба «Алучы» дип аталучы җирлек башкарма комитетлары икенче яктан, бергә «Яклар» дип аталучы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, район Советының ________ 20___ ел, №___ «20__ елга һәм 20__ һәм 20___ еллар план чорына Арча муниципаль районы бюджеты турында» карары, Арча район Советының ________ 20___ ел, №___карары белән расланган территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен башкару өлешендә территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлтелгән чаралар үткәрү өчен финанслау чыганагы Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар булган Арча муниципаль районы бюджетыннан җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибе (алга таба- Башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе) һәм Арча муниципаль районы Башкарма комитетының ________ 20___ ел, №___ күрсәтмәсе нигезендә әлеге Килешүне төзеделәр.

## I. Килешүнең предметы

1.1. Әлеге Килешүнең предметы булып Арча муниципаль районы бюджеты акчаларын алучы буларак Россия Федерациясе бюджетларының чыгымнарын классификацияләү кодлары нигезендә Арча муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүченең коды-828, 01 бүлек, 13 бүлек, 990025180, чыгымнар төре 540 буенча 20__елга_территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләре башкару өлешендә территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлтелгән чаралар үткәрү өчен финанслау чыганагы Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар булган Арча муниципаль районы бюджетыннан җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар (алга таба - Башка бюджетара трансферт) бирү тора.

## II. Башка бюджетара трансферт бирүне финанслау

2.1. Башка бюджетара трансферт Арча муниципаль районы бюджеты акчаларын алучы буларак Башкарма комитетка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә әлеге Килешүнең I бүлегендә күрсәтелгән максатка түбәндәге күләмдә бирелә:

20___ елда ____________________________________________________

## III. Башка бюджетара трансферт бирү шартлары һәм тәртибе

3.1. Башка бюджетара трансферт Арча район Советының ____________20___ ел, № ____ "20__ финанс елына һәм 20__, 20__ еллар план чорына Арча муниципаль районы бюджеты турында" (финанс елына һәм план чорына Арча муниципаль районы бюджетының җыелма бюджет бүленеше (20_,20__ еллар) карарында билгеләнгән бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм Арча муниципаль районы бюджеты акчаларын алучы буларак Башкарма комитетка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3.2. Арча муниципаль районы бюджетыннан Башка бюджетара трансферт Алучының Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органында җирле бюджетлар үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган шәхси счетына әлеге Килешү төзелгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 10 көнлек срокта Килешүнең 2.1 пунктында күрсәтелгән күләмдә күчерелә.

## IV. Якларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Башкарма комитет бурычлы:

4.1.1. Алучы әлеге Килешүдә билгеләнгән Башка бюджетара трансферт бирү шартларын үтәгәндә, Арча муниципаль районы бюджеты акчаларын алучы буларак Башкарма комитетка бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә башка бюджетара трансферт бирүне тәэмин итәргә;

4.1.2. әлеге Килешүнең 3.2 пункты нигезендә күрсәтелгән Башка бюджетара

трансфертны Алучының счетына күчерүне тәэмин итәргә;

4.1.3. Алучы тарафыннан бирелә торган документларны тикшерүне гамәлгә ашырырга;

4.1.4. әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган 1 нче кушымта нигезендә Башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечен билгеләргә;

4.1.5. әлеге Килешүнең аерылгыз өлеше булган 2 нче кушымтада билгеләнгән форма буенча нәтиҗәлелек күрсәткеченә ирешү турындагы хисап нигезендә әлеге Килешүнең 4.1.4 пункты нигезендә Алучы тарафыннан Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченә ирешү буенча йөкләмәләрне исәпкә алып, Башка бюджетара трансферттан файдалануны бәяләүне гамәлгә ашырырга.

4.1.6. Алучы тарафыннан әлеге Килешүдә билгеләнгән Башка бюджетара трансферт бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын үтәүне контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга;

4.1.7. әлеге Килешүдә каралган Башка бюджетара трансферт бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын бозган очраклар булу, дөрес булмаган белешмәләр бирелү фактлары Башкарма комитет яисә Алучы тарафыннан ачыкланган очракта, Башка бюджетара трансфертны кире кайтаруны күрсәтелгән күләмдә һәм срокларда Арча муниципаль районы бюджетына кире кайтаруны тәэмин итү турында таләпне (алга таба - таләп) Алучыга җибәрергә;

4.1.8. әлеге Килешүнең 4.4.2 пункты нигезендә Алучыдан мөрәҗәгать алынганнан соң 10 эш көне эчендә әлеге Килешүнең үтәлешенә бәйле мәсьәләләр буенча Алучыга аңлатмалар җибәрергә;

4.1.9. Россия Федерациясе бюджет законнарында һәм әлеге Килешүдә билгеләнгән башка бурычларны үтәргә.

4.2. Башкарма комитет хокуклы:

4.2.1. әлеге Килешүнең шартларын үзгәртү турында карар кабул итәргә, шул исәптән әлеге Килешүнең 4.4.1 пункты нигезендә Алучы тарафыннан җибәрелгән мәгълүмат һәм тәкъдимнәр нигезендә Башка бюджетара трансферт күләмен киметү турында, шулай ук әлеге Килешүнең 2.1 пунктында күрсәтелгән бюджет йөкләмәләренең файдаланылмаган лимиты булган очракта һәм Алучы тарафыннан әлеге үзгәрешнең финанс-икътисадый нигезләмәсен үз эченә алган мәгълүмат бирелгәндә, Башка бюджетара трансферт күләмен арттыру турында;

4.2.2. Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә әлеге Килешүнең I бүлегендә күрсәтелгән максатларга 20 _ елда файдаланылмаган Башка бюджетара трансферт калдыгын, Алучыдан Башка бюджетара трансферт калдыгын җибәрүгә ихтыяҗны нигезли торган документлар алынганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, агымдагы финанс елында әлеге максатларга башка бюджетара трансферт калдыгыннан артмаган күләмдә Башка бюджетара трансферт ихтыяҗы булу турында карар кабул итәргә;

4.2.3. әлеге Килешүнең 4.1.6 пункты нигезендә Алучыдан әлеге Килешүдә билгеләнгән Башка бюджетара трансферт бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын үтәүне тикшереп тору өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны соратып алырга.

4.2.4. Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

4.3. Алучы бурычлы:

4.3.1. әлеге Килешүнең 1.1 пунктында күрсәтелгән чараны гамәлгә ашыру буенча бурычларны үтәргә;

4.3.2. әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган 1 нче кушымтада билгеләнгән чараны гамәлгә ашыру кысаларында Башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәлелеге күрсәткеченә ирешүне тәэмин итәргә;

4.3.3. әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган 2 нче кушымта нигезендә башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченә ирешү турындагы хисапны һәм әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган 3 нче кушымта нигезендә башка бюджетара трансферттан файдалану турында хисап чорында чыгымнарны гамәлгә ашыруны раслый торган документлар кушымтасы белән хисап бирергә;

4.3.4. Башка бюджетара трансферт чараларын әлеге Килешүнең I бүлегендә күрсәтелгән чарага максатчан һәм нәтиҗәле кулллануны тәэмин итәргә;

4.3.5. Башкарма комитет соравы буенча әлеге Килешүнең 4.1.6 пункты нигезендә башка бюджетара трансферт бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын үтәүне тикшереп тору өчен кирәкле документларны һәм мәгълүматны әлеге сорау кергәннән соң биш эш көне эчендә җибәрергә.

4.3.6. Башка бюджетара трансферт бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен Башкарма комитет һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан тикшерүгә комачауламаска.

4.3.7. Башкарма комитеттан әлеге Килешүнең 4.1.7 пункты нигезендә таләп алынган очракта:

4.3.7.1. күрсәтелгән таләптә билгеләнгән срокларда Башка бюджетара трансферт бирү тәртибен, максатларын һәм шартларын бозу фактын (ларын) бетерергә;

4.3.7.2. Башка бюджетара трансфертны күрсәтелгән таләптә билгеләнгән күләмдә һәм срокларда Арча муниципаль районы бюджетына кире кайтарырга;

4.3.7.3. әлеге Килешү нигезендә Башкарма комитетка тапшырыла торган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген тәэмин итәргә;

4.3.8. хисап елыннан соң килүче финанс елының 1 гыйнварына кадәр файдаланылмаган Башка бюджетара трансферт акчаларының калган өлешен Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән срокларда Арча муниципаль районы бюджетына кире кайтарырга;

4.3.9. Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә башка бурычларны үтәргә.

4.4. Алучы хокуклы:

4.4.1. Башка бюджетара трансферт күләмен үзгәртү зарурилыгы билгеләнгән

очракта, әлеге Килешүгә үзгәрешләр кертү турында, шул исәптән әлеге үзгәрешнең финанс-икътисадый нигезләмәсен үз эченә алган мәгълүматны кушып, Башкарма комитетка тәкъдимнәр җибәрергә;

4.4.2. әлеге Килешүнең үтәлеше белән бәйле аңлатмалар алу максатыннан, Башкарма комитетка мөрәҗәгать итәргә;

4.4.3. Башкарма комитет тарафыннан әлеге Килешүнең 4.2.2 пункты нигезендә Башка бюджетара трансфертның тиешле калдыгын кире кайтарган очракта, әлеге Килешү нигезендә алынган Башка бюджетара трансфертның кулланылмаган калдыгын (булганда) әлеге Килешүнең I бүлегендә күрсәтелгән максатлар өчен түләүләр башкару өчен җибәрергә;

4.4.4. Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

## V. Якларның җаваплылыгы

5.1. Әлеге Килешү шартларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен Яклар Россия Федерациясе законнарында каралган җаваплылыкка ия.

5.2. Алучы әлеге Килешүдә каралган бурычларның берсен үтәмәгән, әлеге Килешүдә каралган документларны һәм хисапларны тапшырмаган яки үз вакытында тапшырмаган очракта, әлеге Килешүнең 4.1.4 пункты нигезендә билгеләнгән башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченә ирешмәгән, дөрес булмаган белешмәләр биргән очракта, Башкарма комитет, әлеге Килешүне вакытыннан алда өзү турында хәбәрнамә юллау юлы белән, хәбәрнамә алынган көннән соң 10 көн эчендә Башка бюджетара трансферт акчаларын кире кайтаруны таләп итеп, өзәргә хокуклы.

5.3. Хисап финанс елында кулланылмаган Башка бюджетара трансферт акчалары булган очракта, калган акчалар хисап елыннан соң киләчәк торган елның беренче 15 эш көне эчендә Арча муниципаль районы бюджеты керемене кире кайтарылырга тиеш.

## VI. Контроль һәм хисап

6.1. Алучы Башкарма комитетка түбәндәгеләрне җиткерә:

6.1.1. әлеге Килешүнең 4.3.3 пункты нигезендә әлеге Килешүнең 2 нче кушымтасындагы форма буенча 20__ елның 15 гыйнварына кадәр башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәлелеге күрсәткеченә ирешү турында хисап.

6.1.2. әлеге Килешүнең 4.3.3 пункты нигезендә квартал саен хисап чорыннан соң килүче айның 7 числосына кадәр әлеге Килешүнең 3 нче кушымтасындагы форма буенча вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан расланган чыгымнарны раслый торган документларның күчермәләре белән Башка бюджетара трансферттан файдалану турында хисап.

6.2. Башка бюджетара трансферт акчаларының максатчан кулланылышын контрольдә тоту Башкарма комитет тарафыннан әлеге Килешүнең 6.1 пунктында күрсәтелгән хисаплар нигезендә гамәлгә ашырыла.

## VII. Килешүнең гамәлдә булу вакыты

7.1. Әлеге Килешү Яклар кул куйганнан соң үз көченә керә һәм 20_ елның 15 гыйнварына кадәр гамәлдә була.

7.2. Килешүнең гамәлдә булу вакытын туктату Алучыны Килешүнең 4.3.3, 4.3.5, 6.1.1, 6.1.2 пунктлары нигезендә Башкарма комитетка хисап бирү буенча бурычлардан азат итми.

## VIII. Башка шартлар

8.1. Әлеге Килешүгә карата теләсә нинди үзгәрешләр һәм өстәмәләр бары тик алар тиешенчә язма рәвештә рәсмиләштерелгән һәм Якларның вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имзаланган очракларда гына гамәлдә була.

8.2. Әлеге Килешүне үтәү барышында барлыкка килергә мөмкин булган барлык бәхәсләр һәм каршылыклар Якларның сөйләшүләре һәм консультацияләр юлы белән хәл ителәчәк.

8.3. Бәхәсләрне сөйләшүләр һәм консультацияләр юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, бәхәсләр суд тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә хәл ителергә тиеш.

8.4. Әлеге Килешү ике нөсхәдә, бер нөсхә - Башкарма комитет өчен, берсе Алучы өчен төзелде.

8.5. Алучы Башкарма комитет һәм муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан Башка бюджетара трансферт бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен, шулай ук әлеге Килешүне тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалык бирә.

## IX. Якларның юридик адреслары һәм реквизитлары

| | |
|---|---|
| Арча муниципаль районы башкарма комитеты<br>422000, ТР, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 12 нче йорт<br>Татарстан Республикасы Казан шәһәре НБ бүлеге<br>БИК 049205001<br>к/с-<br>Р / с - 40204810100000000029<br>Алучы: ТР буенча ФКИ (ТР Арча муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы) л / с 04113000100<br>ИНН/КПП 1609009548/160901001<br>ОГРН 1061685000299<br>ОКТМО 92612000 | |

Якларның имзалары

Арча муниципаль районы башкарма комитет җитәкчесе

_______________/

Алучы:

_______________/

Территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә
компенсация түләүләрен башкару өлешендә
территориаль иҗтимагый үзидарә системасын
үстерүгә юнәлтелгән чаралар үткәрү өчен
финанслау чыганагы Татарстан Республикасы
бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар
булган Арча муниципаль районы бюджетыннан
җирлекләр бюджетларына
башка бюджетара трансфертлар бирү турында
Килешүгә 1 нче кушымта

Башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечене

| Чаралар атамасы | Күрсәткечнең атамасы | Үлчәү берәмлеге ОКЕИ буенча | | пландагы күрсәткеч | Күрсәткечкә ирешүнең планлаштырылган срогы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Атамасы | Код | | |
| 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| Территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен башкару өлешендә Арча муниципаль районы территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерү | Җитәкчеләргә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыруга башка бюджетара трансферт рәвешендә ярдәм күрсәтелгән ТИҮ саны | берәмлек | 642 | 5 | 31.12.2[illegible] |

Арча муниципаль районы
башкарма комитет җитәкчесе

Алучы:

_______________/

_______________/

“Территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә
компенсация түләүләрен башкару өлешендә
территориаль иҗтимагый үзидарә системасын
үстерүгә юнәлтелгән чаралар үткәрү өчен
финанслау чыганагы Татарстан Республикасы
бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар
булган Арча муниципаль районы бюджетыннан
җирлекләр бюджетларына
башка бюджетара трансфертлар бирү турында

Килешүгә 2 нче кушымта

______________ 20__ елга башка бюджетара трансфертлар
куллану нәтиҗәлелеге күрсәткечենә ирешү турында хисап

Алучының исеме________________________________________
Ешлыгы: еллык

| | Чаралар атамасы | Күрсәткеч атамасы | Пландагы күрсәткеч | Хисап бирү датасына ирешелгән күрсәткеч | План үтәлеше күрсәткече | Тайпылуның сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |

Хисап кабул ителде:

Алучы җитәкчесе______________ ________________________________
(вәкаләтле зат) *(вазыйфасы, имза, имзаны аңлату)*

Башкаручы ___________________ __________________________
(вазыйфасы, ФИАИ, телефон) *(вазыйфасы, имза, имзаны аңлату)*
«___» __________ 20 ___ел «___» ____________ 20 ___ел

Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе

Алучы:

______________/____________/

______________/ _________________/

Территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә
компенсация түләүләрен башкару өлешендә
территориаль иҗтимагый үзидарә системасын
үстерүгә юнәлтелгән чаралар үткәрү өчен
финанслау чыганагы Татарстан Республикасы
бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар
булган Арча муниципаль районы бюджетыннан
җирлекләр бюджетларына
башка бюджетара трансфертлар бирү турында
“_23_”_июнь_______2020_ел

Килешүгә 3 нче кушымта

Форма

“___”____________________ 20__ елга Башка бюджетара
трансферттан файдалану турында хисап

Вәкаләтле орган исеме ______________________________

Ешлыгы: квартал саен

Үлчәү берәмлеге: сум (икенче унлы билгегә кадәр)

| Күрсәткеч атамасы | Сумма | | Чыгымнарны гамәлгә ашыруны раслый торган документларның реквизитлары |
|---|---|---|---|
| | Хисап чоры | Ел башыннан бирле үсеп килүче нәтиҗә | |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Агымдагы финанс елы башына Башка бюджетара трансферт калдыгы, барлыгы | | | |
| шул исәптән: расланган ихтыяҗ | | | |
| Арча муниципаль районы бюджетына кире кайтарылырга тиеш | | | |
| Башка бюджетара трансферт чаралары, барлыгы | | | |
| Хисап датасына касса чыгымнары, барлыгы | | | |
| Арча муниципаль районы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акчалар, барлыгы | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| шул исәптән:<br>максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган | | | |
| Арча муниципаль районы бюджетына барлыгы кире кайтарылды | | | |
| шул исәптән: | | | |
| агымдагы финанс елы башына Арча муниципаль районы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акча калдыгы | | | |
| Арча муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле акчалар | | | |
| шулардан:<br>максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган | | | |
| Хисап чоры ахырына башка бюджетара трансферт калдыгы, барлыгы | | | |
| шул исәптән:<br>Арча муниципаль районы бюджетына кире кайтарылырга тиеш | | | |

Хисапка әлеге таблицаның 4 нче графасында санап үтелгән чыгымнарны гамәлгә ашыруны раслый торган документларның тиешенчә расланган күчермәләре теркәлә.

Алучы _______________ ___________ ___________________________

(вазыйфасы) (имза) (имзаны аңлату)

Башкаручы _______________ _______________ _______________

(вазыйфасы) (Ф. и. а.и.) (телефон)

«___» ___________ 20__ ел

Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе

_____________/

Алучы:

_____________/

Форма
Арча район Советының
23 июнь 2020ел, №334
карары белән расланган
Арча муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесенә
________________________________

Компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру максатыннан җитәкчегә Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидия алу өчен

ГАРИЗА

________________________________________________________________
(территориаль иҗтимагый үзидарә атамасы)

Арча район Советының «____» ______________ 2020ел, №______ «Территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен башкару өлешендә территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлтелгән чаралар үткәрү өчен финанслау чыганагы Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар булган Арча муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» карарын тормышка ашыру максатыннан, территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өчен 20__ елның _____ аена ______________ сум күләмендә башка бюджетара трансфертлар бирүегезне сорыйм.

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Атамасы | |
| 2 | ИНН | |
| 3 | КПП | |
| 4 | ОГРН | |
| 5 | ОКПО | |
| 6 | ОКВЭД | |
| 7 | Юридик адресы | |
| 8 | Факттагы адресы | |
| 9 | Элемтә өчен телефон/факс | |
| 10 | Почта адресы | |
| 11 | Банк реквизитлары | |
| 12 | Җитәкченең исем-фамилиясе | |
| 13 | Баш хисапчының исем-фамилиясе | |

Җитәкче имза
Гариза бирү датасы

М. у.